ЭШЧӘН ПЕСИ

такмаклар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1994

ТЫЧКАН ҖИГӘЛӘР

Алай итәләр аны,
Болай итәләр аны,
Чабатага тычкан җигеп
Гуляйт итәләр аны.

ЙОКЛАП ЯТА

Чуар тавык суга бара,
Аягында чабата.
Шул вакытта, оялмыйча,
Ата каз йоклап ята.

МИНЕ ЧАКЫР

Тәк-тәк, тәкүшкә,
Тәкә кергән инешкә,
Күрмәдеңме, дәдюшкә?
Суймадыңмы бәлешкә,
Суйган булсаң бәлешкә,
Мине чакыр өлешкә.

БИЕП ЙӨРИ

Иртән торып тышка чыксам,
Тараканнар кар көри.
Чикерткәләр, туфли киеп,
Урамда биеп йөри.

КӨРӘШӘЛӘР

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр капчыклар.
Түбән очка менгән идем,
Көрәшәләр карчыклар.

КАРАП КАЛА

Ике песи суга бара,
Көянтә, чиләк асып.
Ике тычкан карап кала,
Капка төбенә басып.

АТЛАРЫ ҖЫРЛЫЙ

Сары, сары, сап-сары
Сары пәке саплары.
Сараларга барган идем,
Җырлый икән атлары.





КУНАККА БАРАМ

Көзгегә карыйм әле,
Чәчемне тарыйм әле,
Әбиләргә бер атнага
Кунакка барыйм әле.



ӘТӘЧ АГАЙ

Ике тавык бакча казый,
Итәкләрен кыстырып.
Әтәч агай трубка тарта,
Күләгәгә утырып.

УҢГАН ПЕСИ

Безнең песи бигрәк уңган,
Комганга су тутыра.
Бозавыбыз мич башында,
Оек бәйләп утыра.

ТИБЕП ТӨШЕРДЕ

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр өтерге.
Куначага менгән идем,
Әтәч тибеп төшерде.

АВЫЗЫҢНЫ ЗУР АЧМА

Кибәргә элгән керләрем
Җилгә очып китмәсен.
Авызыңны бик зур ачма,
Карга кереп китмәсен.



БАЛАГЫ ӨСТЕРӘЛӘ

Син кәбестә карагы,
Син кәбестә карагы.
Атаң ыштанын кигәнсең,
Өстерәлә балагы.



ЧАБУЫННАН ТАРТ

И, ак көчек, ак көчек,
Сәке астында ят, көчек.
Түрдә утырган кунак кызның
Чабуыннан тарт, көчек.

ИШЕК АЧЫГЫЗ

Безнең дә бар мәчебез,
Сезнең дә бар мәчегез.
Безнең мәче сезгә килсә,
Зинһар, ишек ачыгыз.

СИН КАРАП ТОР

Фәрхетдин кәҗә симертә,
Тал кайрысын кимертә.
Хәмит абзый, син карап тор,
Нәби бака сикертә.

ЭЧТӘЛЕК

Тычкан җигәләр 1
Йоклап ята 2
Мине чакыр 3
Биеп йөри 4
Көрәшәләр 5
Карап кала 6
Атлары җырлый 7
Кунакка барам 8
Әтәч агай 9
Уңган песи 10
Тибеп төшерде 11
Авызыңны зур ачма 12
Балагы өстерәлә 13
Чабуыннан тарт 14
Ишек ачыгыз 15
Син карап тор 16



Рəссамы ДАМИР ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ
Такмакларны җыючы РӘШИТ ЯГЪФӘРОВ

Кече яшьтәге балаларга

КОТ-РАБОТЯГА

Татарский детский фольклор

(на татарском языке)

ИБ № 6518

Мөхәррире *Б. Рәхимова.* Бизәлеш мөхәррире *Р. Шәмсетдинов.* Техник мөхәррире *Ф. Гыйсмәтуллина.* Корректоры *М. Фәйзуллина.* Җыярга тапшырылды 24.01.94. Басарга кул куелды 29.06.94. Форматы 60×90 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе № 1. Гарнитурасы «Литературная». Офсет басма. Басма табагы 1,0. Шартлы буяу-оттиск 5.0. Нәшер-хисап табагы 1,47. Тиражы 50000 экз. Заказ А-37. Татарстан китап нәшрияты, 420084, Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство, 420084, Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан газета-журналлар нәшрияты. 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Э $\frac{4803560204—040}{М132\ (03)—94}$ 116—94 ББК 82.3 (2 Тат)

ISBN 5—298—00481—4

© Татарстан китап нәшрияты, 1994